Исполнительный комитет
Тураевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
ул. Центральная д. 11 А, с. Тураево
Менделеевский район, 423647

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай
авыл җирлеге башкарма комитеты
Үзәк урам, 11А, Турай авылы,
Менделеевск районы, 423647

тел./факс (85549) 2-73-31

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

27.03.2025 ел № 8

Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге
башкарма комитетының “Хуҗасыз хайваннарны кайтару
тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны
элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында
карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү
һәм Турай авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын
йөртү урыннарын билгеләү хакында” 2025 елның
3 мартындагы 25 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Уставы нигезендә. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә буш урыннар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар, борынчыкларда һәм муенчакларда аларның хуҗалары күзәтүе астында;

- Турай авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә Тынычлык урамыннан 200 метр ераклыкта, (урман полосасы ягына туфрак юл), көньяк өлешендә Яшьләр урамыннан 150 метр ераклыкта ( Кама елгасы ягына туфрак юл), көньяк – көнчыгыш өлешендә Окольная урамыннан 150 метр ераклыкта (урман утырту ягына туфрак юл);

- Татар Әхтиялы авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә, Чишмә урамыннан 150 метр ераклыкта (иске ферма территориясе)

Әлеге территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дигән язулы табличкалар куярга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Турай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова